ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БОЛЬШЕКАЧКИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ОЛЫ КАЧЫК АВЫЛЫ

БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **Олы Качык авылы** **КАРАР**

№ 3 5 декабрь, 2019 ел

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы
Олы Качык авыл җирлегенең Олы Тарлау торак пунктында
гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе
буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының Олы Качык авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставның 22 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Олы Качык авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Олы Качык авыл җирлегенең Олы Тарлау торак пунктының Югары урам, Качык урамы, Өрәңгеле урамы буенча 2019 елның 17 декабренә 18 сәгатькә Качык урамы, 38 Б йортында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Олы Качык авыл җирлегенең Олы Тарлау торак пункты буенча 2019 елның 17 декабренә 19 сәгатькә Түбән урам, 1А йортында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Олы Качык авыл җирлегенең Олы Тарлау торак пунктының Нократ урамы буенча 2019 елның 17 декабренә 20 сәгатькә Качык урамы, 48 А йортында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Олы Качык авыл җирлегенең Олы Тарлау торак пунктында яшәүчеләр исемлеген территориаль билге буенча бүләргә.

4. Гражданнар җыенына тәкъдим ителгән сорауларны расларга:

«Сез Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Олы Качык авыл җирлегенең Олы Тарлау торак пункты чикләрендә урнашкан даими яшәүче гражданнар һәм 18 яшькә җиткән кешеләр өчен 200 (ике йөз) сум күләмендә, гомуми авырудагы инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләр ветераннары, сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның тол хатыннарына, күпбалалы гаиләләр, югары һәм урта-махсус (урта-һөнәри) уку йортларында белем алучы студентлар өчен 100 (йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкру буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?»

- Алабуга муниципаль районы Олы Качык авыл җирлегенең Олы Тарлау торак пунктында балалар мәйданчыгы территориясен төзекләндерү.
- “ӘЙЕ” - “ЮК”

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Җитәкче А.А. Голованов